РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Алькеевский муниципальный
район Совет Староалпаровского
сельского поселения

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
Иске Алпар авыл җирлеге Советы

Адрес: 422877, РТ, Алькеевский
район с.Старое Алпарово ,
ул.Северная , 29
тел: 8 (84346) 72553

Адресы: 422877, РТ, Әлки районы,
Иске Алпар а вылы,
Тоньяк ур,29 й
тел: 8 (84346)72553

**РЕШЕНИЕ** Иске Алпар авылы **КАРАР**

2024нче елның 13нче ноябре 102 №

2022елның " 15" декабрендәге Әлки муниципаль
районы Иске Алпар авыл җирлегенең
46 номерлы«Әлки муниципаль районы
Иске Алпар җирле үзидарә
муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре,
депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә
гамәлгә ашыручы үзидарәләрнең,
хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында
Нигезләмәне раслау турында"гы
Карарына үзгәрешләр кертү турында

2018нче елның 28нче мартындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең, депутатларның, җирлеүзидарәнең үз вәкаләтләрен даиминигездә гамәлгә ашыручы сайлаңулы вазыйфаизатларның, рәисләрнең, рәис урынбасарларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары аудиторларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында"гы 182№ (2018нче елның 24 апрелендәге 281№, 2018нче елның 14нче июнендәге 481№, 2018нче елның 17нче октябрендәге 940№, 2018нче елның 29нчы декабрендәге 1320№, 2021нче елның 17нче ноябрендәге 1087№, 2021нче елның 13нче декабрендәге 1222№, 2022нче елның 17нче сентябрендәге 1015№, 2024нче елның 30нчы апрелендәге 290№, 2024нче елның 24нче июнендәге 451№, от 2024нче елның 25нче сентябрендәге 829№ Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән),Әлки муниципаль районы Иске Алпар җирле үзидарә Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1.2022 елның 15нче декабрендәге Әлки муниципаль районы Иске Алпар авыл җирлеге Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Әлки муниципаль районы Иске Алпар авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 60 номерлы карарына (2024 елның 16 маендагы 93 номерлы редакциядә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта түбәндәге абзац өстәргә:

01.01.2025 елдан Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Алпар авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләменә бер тапкыр исәпләнә, ул 13990сум тәшкил итәчәк.

2. 1 нче кушымтаны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның http://pravo.tatarstan.ru.рәсми порталында бастырып чыгарырга

4.Әлеге карар2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Әлки муниципаль районы
Иске Алпар авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Р.Салахов

2024нче елның 13 нче ноябрь
Әлки муниципаль районы Иске
Алпар җирле үзидарә Советының
102 нче карарына
1нче кушымта

**2025 НЧЕ ЕЛНЫҢ 1НЧЕ ГЫЙНВАРЕННАН ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫНЫҢ ИСКЕ АЛПАР ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘСЕНДӘ ДЕПУТАТЛАРНЫ, ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ ҮЗ ВӘКАЛӘТЛӘРЕН ДАИМИ НИГЕЗДӘ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ САЙЛАНУЛЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫ, ИСКЕ АЛПАР ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК БАШЛЫГЫНЫҢ АЙЛЫК АКЧАЛАТА БҮЛӘКЛӘҮ КҮЛӘМНӘРЕ**

| Вазыйфа исеме | Айлык акчалата түләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | авыл җирлекләрендә |
| | 12 нчы төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 19173 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 13 991 |
| Депутат | 13990 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы | 13990 |